КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 30 декабрь г.Казань № 1141

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга эш бирүчеләрнең чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2007 ел, 5 февраль, 32 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга эш бирүчеләрнең чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2007 ел, 5 февраль, 32 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Карарга теркәлгән Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен расларга.»;

4 пунктта «Татарстан Республикасы Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «Татарстан Республикасы Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин